ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

08.05.2020 ел Баулы шәһәре №102

“2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү” муниципаль программасын раслау турында

2007 елның 4 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында”гы 329-ФЗ санлы Федераль закон (2019 елның 2 августында редакцияләнгән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартында кабул ителгән “2019-2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында”гы 159 санлы карары (2019 елның 30 декабрендә редакцияләнгән) нигезендә, территориядә физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, физик культура һәм спортны үстерү өчен шартлар булдыру максатыннан, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымта рәвешендә теркәлгән “2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү” муниципаль программасын (алга таба – Программа) расларга.
2. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесен Программаны башкару буенча, Программаның вакытында һәм тулы күләмдә үтәлешен контрольдә тоту буенча җаваплы орган итеп билгеләргә.
3. Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына ел саен, киләсе елга Баулы муниципаль районы бюджетын формалаштырганда, Программа чараларын тормышка ашыруга акча күздә тотарга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 8 маенда кабул ителгән
102 санлы карар белән
расланган

# “2020-2024 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТНЫ ҮСТЕРҮ” МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

Баулы шәһәре – 2020 ел.

## ПАСПОРТ ПРОГРАММАСЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү” муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | - 2007 елның 4 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында”гы 329-ФЗ санлы Федераль закон;<br>- 1995 елның 24 ноябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы 181-ФЗ санлы Федераль закон;<br>- Татарстан Республикасының 2008 елның 8 октябрендә кабул ителгән “Физик культура һәм спорт турында”гы 99-ЗРТ санлы Законы;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 1 декабрендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең 2019-2020 елларга “Уңайлы мохит” дәүләт программасын раслау турында”гы 1297 санлы карары;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендә кабул ителгән “Россия Федерациясенең “Физик культура һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында”гы 302 санлы карары;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 7 августында кабул ителгән “2020 елга кадәрге чорда Россия Федерациясендә физик культура һәм спортны үстерү Стратегиясен раслау турында”гы 1101-р санлы боерыгы;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартында кабул ителгән “2019-2021 елларга Татарстан Республикасында физик культура һәм спортны үстерү” дәүләт программасын раслау турында”гы 159 санлы карары;<br>- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабрендә кабул ителгән “2014-2021 елларга “Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү” дәүләт программасын раслау турында”гы 1023 санлы карары;<br>- 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисади үстерү стратегиясе;<br>- “Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды” коммерцияле булмаган оешмасы эшләгән, 2016-2020 елларга Татарстан Республикасының социаль тармакларын һәм җәмәгать инфраструктурасын үстерү концепциясе. |
| Программаның муниципаль заказчысы-координаторы Программы | “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны төп эшләүче | “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары | 1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру.<br>2. Спорт белән шөгыльләнү һәм спортта югары нәтиҗәләргә ирешү өчен шартлар булдыру. |
| Программаның бурычлары | 1. Баулы муниципаль районы халкының системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә, сәламәт тормыш рәвеше алып бару теләген арттыру.<br>2. Спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү һәм Баулы муниципаль районы спортчыларының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма командалары составында уңышлы катнашуларын тәэмин итү. 3. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте нәтиҗәлелеген арттыру. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2020 - 2024 еллар |
| Программаны финанслау күләмнәре (еллар һәм чыганаклар буенча) | Программаны 2020-2024 елларда финанслауның гомуми күләме 170 518,5 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2020 ел - 56 734,2 мең сум;<br>2021 ел - 55 466,4 мең сум;<br>2022 ел - 55 911,3 мең сум;<br>2023 ел - 1 203,3 мең сум;<br>2024 ел - 1 203,3 мең сум.<br>Искәрмә:<br>Программаны финанслау фаразлау характерында, елга һәм планлы чорга Баулы муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төгәллек кертү зарур. Республика, җирле бюджет акчалары ел саен төзелгән килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |
| Ярдәмче программалар исемлеге | 1. “2020-2024 елларга физик культура һәм спортны үстерү”<br>2. “2020-2024 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү”. |

| | |
|---|---|
| Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 елга түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:<br>- халыкның гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен 63 процентка кадәр;<br>- “Хезмәткә һәм оборонага әзер!” Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән кешеләрнең өлешен “Хезмәткә һәм оборонага әзер!” Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми өлешендә 61 процентка кадәр;<br>- сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрнең гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләренең өлешен 19 процентка кадәр;<br>- физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүче (шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләргә) оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;<br>- спорт әзерлеген тормышка ашыручы оешмаларда спорт ягыннан камилләшү этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген тормышка ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 9 процентка кадәр;<br>- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма командалары составына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар санын 5 кешегә кадәр. |

## I. Программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләргә характеристика

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү социаль сәясәтнең өстенлекле юнәлеше булып тора һәм ышанычлы норматив-хокукый нигезгә нигезләнә Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә киң мөмкинлекләр булдырыла.

Баулы районы халкын системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә җәлеп итү максатыннан, спорт инфраструктурасын модернизацияләү һәм төрле яшьтәгеләрнең спорт корылмаларында шөгыльләнү мөмкинлеген арттыру буенча эш алып барыла. Хәзерге вакытта Баулы районында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр саны 15019 кеше тәшкил итә, ягъни район халкының 47,03 проценты.

Районда 3 спорт мәктәбе эшли. Аларда 1202 кеше шөгыльләнә, 15 спорт төре буенча дәресләр үткәрелә. Спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүчеләр бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашалар һәм җиңәләр. Баулы районында хоккей, футбол,

волейбол, баскетбол, көрәш, йөзү, чаңгыда шуу, җиңел атлетика, өстәл теннисы, бокс белән шөгыльләнүчеләр аеруча күп. Ел саен районда 60тан артык спорт чарасы уздырыла.

Төрле милекчелек формаларындагы предприятиеләрдә физик культура һәм спорт юнәлешендә актив эш алып барыла. Халыкны сәламәт тормыш рәвешенә җәлеп итүнең бер формасы – массакүләм физкультура һәм спорт ярышлары үткәрү. Мәсәлән, “Россия чаңгы юлы” Бөтенроссия чаңгы ярышлары һәм “Милләтләр кроссы” Бөтенроссия йөгереше кысаларында ярышлар оештырыла.

Баулы районында адаптив спорт динамикалы рәвештә үсешкә ирешә, физик күнегүләр белән шөгыльләнүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр саны арта, адаптив спортның яңа төрләре үсешкә ирешә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм итүче “Я СМОГУ” автоном, коммерциянеке булмаган оешмасы эшли. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында 2 спорт төре буенча ярышлар үткәрелә. Район ярышларында катнашып, спорт уңышларына ирешүче аерым командалар һәм инвалид спортчылар да бар.

Шул ук вакытта, спорт өлкәсен алга таба үстерүгә түбәндәге проблемалар киртә булып тора:

1. Физик культура һәм массакүләм спорт тотрыклы үсешкә ирешсә дә, халык белән, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр белән физкультура-спорт эшен оештыру белән бәйле проблемалар бар, шул исәптән финанслар һәм кадрлар, йорт яны территорияләрен физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен төзекләндерү белән бәйле проблемалар.

2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә иң көнүзәк проблемаларның берсе – 2008 елга кадәр төзелгән спорт корылмаларының матди-техник яктан тузуы. Әлеге спорт биналары халыкара спорт федерацияләре таләпләренә җавап бирми. Төрле дәрәҗәдәге ярышлар уздырганда куркынычсызлык тәэмин итү ягыннан әлеге объектларга таләпләр ел саен арта, ягъни ул корылмалар аңа туры килми.

Әлеге проблемаларны хәл итү өчен, “2020-2024 елларга физик культура һәм спортны үстерү” ярдәмче программасы кысаларында, спорт инфраструктурасын һәм спорт учреждениеләре челтәрен үстерүгә, аларның нәтиҗәлелеген арттыруга, балалар-яшүсмерләр массакүләм спортын һәм спорт резервын әзерләүне үстерүгә, студентлар спортын үстерүгә, барлык төр категория кешеләр арасында массакүләм спортны үстерүгә, өстенлекле спорт төрләрен үстерүгә шартлар тудыруга, югары класслы спортчылар әзерләүгә, физик культура һәм спорт буенча югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә ярдәм итүгә, халыкның даими рәвештә физик культура һәм спорт

белән шөгыльләнергә теләген формалаштыруга, халык арасында сәламәт тормыш рәвешен пропагандалауга, физик культура һәм спорт өлкәсен фәнни һәм мәгълүмати-методик тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар комплексы тәкъдим ителә.

“2020-2024 елларга спорт резервын әзерләү системасын һәм югары казанышлар спортын үстерү” ярдәмче программасы кысаларында, Баулы районында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен спорт резервын сайлап алу һәм әзерләү системасын камилләштерүгә, Баулы районы спортчыларының рәсми төбәкара, Бөтенроссия һәм рәсми халыкара спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләренә ирешүенә юнәлдерелгән чаралар үткәрелә.

Ел саен Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Баулы муниципаль районы арасында физик культура һәм спортны үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелә.

## II. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның төп максатлары – Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, спорт белән шөгыльләнү һәм югары спорт нәтиҗәләренә ирешү өчен шартлар тудыру.

Куелган максталарга ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:

1. Баулы муниципаль районы халкының физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә, сәламәт яшәү рәвешен алып бару теләген арттыру.

2. Спорт резервын әзерләү системасын камилләштерү һәм Баулы муниципаль районы спортчыларының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара спорт ярышларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма командалары составында уңышлы катнашуларын тәэмин итү.

3. Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәте нәтиҗәлелеген арттыру.

Куелган бурычларның күләмле булуы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

Физик культура һәм спортны үстерү, халыкның сәламәтлеген ныгыту, Баулы районының спорт имиджын ныгыту өчен “2020-2024 елларга физик культура һәм спортны үстерү” ярдәмче программасы тормышка ашырыла.

Ярдәмче программа сәламәт тормыш рәвешен формалаштыруга, сәламәтлекне ныгытуга, физик активлыкны һәм халыкның барлык яшь төркемнәренең әзерлеген арттыруга, тулы канлы ял һәм сәламәт ял өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Әлеге чараларны гамәлгә ашыру Баулы районы халкының сәламәтлеген ныгыту өчен шартлар тудырырга, Баулы районындагы демографик хәлне яхшыртырга, массакүләм спортны үстерергә һәм популярлаштырырга, җәмгыятьнең төрле катламнарын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 елга түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:

- халыкның гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең өлешен 63 процентка кадәр;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрнең гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләренең өлешен 19 процентка кадәр;

- “Хезмәткә һәм оборонага әзер!” Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән кешеләрнең өлешен “Хезмәткә һәм оборонага әзер!” Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми өлешендә 61 процентка кадәр;

Спорт резервын әзерләүне һәм Татарстан Республикасы спортчыларының Россия һәм халыкара спорт ярышларында уңышлы чыгыш ясауларын тәэмин итү максатыннан “2020-2024 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү” ярдәмче программасы гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа спорт резервын әзерләүгә, спорт мәктәпләрендә укучыларның спорт нәтиҗәләрен камилләштерүгә, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлекне фәнни, аналитик һәм методик тәэмин итү системасына ярдәм итүгә, балаларга өстәмә белем бирү оешмаларына һәм спорт юнәлешендәге һөнәри белем бирү оешмаларына ярдәм итүгә, югары казанышлар спортын үстерүгә (һөнәри спорт) юнәлтелгән чараларны башкаруны күздә тота.

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2024 елга түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма командалары составына кандидатлар исемлегенә кертелгән спортчылар санын 5 кешегә кадәр;

- физик культура һәм спорт өлкәсендәге оешмаларның гомуми санында спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә спорт әзерлеге буенча хезмәт күрсәтүче (шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләргә) оешмалар өлешен 100 процентка кадәр;

- спорт әзерлеген тормышка ашыручы оешмаларда спорт ягыннан камилләшү

этабында шөгыльләнүчеләрнең гомуми санында спорт әзерлеген тормышка ашыручы оешмаларда югары спорт осталыгы этабында шөгыльләнүчеләр өлешен 9 процентка кадәр;

Программа 2020-2024 елларда тормышка ашырылачак.

III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны 2020-2024 елларда финанслауның гомуми күләме 170 518,5 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2020 ел - 56 734,2 мең сум;

2021 ел - 55 466,4 мең сум;

2022 ел - 55 911,3 мең сум;

2023 ел - 1 203,3 мең сум;

2024 ел - 1 203,3 мең сум.

Программаны финанслау фаразлау характерына ия, елга һәм планлы чорга Баулы муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төгәллек кертү зарур. Республика, җирле бюджет акчалары ел саен төзелгән килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

IV. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны тормышка ашыру һәм анда катнашучылар эшчәнлеген координацияләү өчен җаваплы орган булып “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесе санала.

“Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесе түбәндәгеләрне эшли:

программа чаралары исемлегенә, аларны тормышка ашыру чыгымнарына төгәллек кертү буенча билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәр әзерли;

максатчан индикаторлар исемлеген һәм аларны квартал саен бүлүне аныклый;

ел саен программаны тормышка ашыруның барышы турында хисап әзерли, ул Баулы муниципаль районы Советы утырышында, яки Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты утырышларында, яисә профильле комиссияләр утырышларында тыңлана;

ел саен, хисаптан соң килүче елның мартына кадәр, шулай ук Муниципаль программаны гамәлгә ашыру вакыты тәмамланганнан соң, муниципаль программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеге турында хисап җибәрә.

V. Программаны тормышка ашыруның икътисади, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның социаль-икътисади нәтиҗәлелегенә түбәндәгеләр хисабына ирешеп булачак:

Баулы муниципаль районының физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче кешеләр санын арттыру;

халыкның төрле төркемнәре арасында авырулар санының кимүе;

оештырылмаган төркем балаларны һәм яшьләрне спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;

физкультура-спорт хезмәтләренең, шул исәптән түләүле хезмәтләрне алу мөмкинлеген, аларның төрлелеген һәм сыйфатын арттыру;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрнең физик тернәкләнү һәм социаль адаптация өчен мөмкинлекләрен киңәйтү;

район гражданнарының сәламәтләндерүдә актив ял итү рәвешләренә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү;

яшьләр арасында наркоманияне, алкоголизмны, тәмәке тартуны һәм хокук бозуларны профилактикалауның нәтиҗәле системасын булдыру, шул исәптән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү юлы белән дә;

спорт инфраструктурасының тотрыклы үсеше һәм нәтиҗәлелеген арттыру;

халык арасында авыручылар саны кимү һәм гомер озынлылыгы арту нәтиҗәсе буларак, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга ирешү.

VI. “2020-2024 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ФИЗИК
КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТНЫ ҮСТЕРҮ”
МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ чаралары исемлеге

| № п/п | Чара исеме | Җаваплы башкаручылар | Башкару вакыты | Финанслау чыганагы, күләме | Шул исәптән еллар буенча (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | | | | |
| I. | “2020-2024 елларга физик культура һәм спортны үстерү” ярдәмче программасы чаралары исемлеге | | | | | | | | |
| 1. | Район спортчыларының республика, Россия һәм халыкара ярышларына әзерләүне һәм аларны катнашуларын тәэмин итү | “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризмны үстерү бүлеге” муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге) | 2020-2024 еллар | җирле бюджет | 841,90 | 841,90 | 841,90 | 841,90 | 841,90 |
| 2. | “Авыл яшьләре спартакиадасы”, “Милләтләр кроссы”, “Россия чаңгы юлы”, “Сәнәгать предприятиеләре, оешмалары учреждениеләре спартакиадасы”, “Спорт уеннары | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | җирле бюджет | 292,40 | 292,40 | 292,40 | 292,40 | 292,40 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестивале” популяр спорт-массакүләм чаралары уздыру юлы белән район халкының төрле төркемнәре арасында сәламәт һәм актив тормыш рәвешен пропагандалау | | | | | | | | |
| 3. | Инвалидлар һәм өлкән яшьтәге кешеләр арасында бильярд, шашка, шахмат, йөзү, өстәл теннисы, җиңел атлетика буенча спорт ярышлары, спартакиадалар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре уздыру | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | жирле бюджет | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| 4. | Татарстан Республикасының календарь планы буенча инвалидларның һәм өлкән яшьтәге затларның республика ярышларында катнашуын тәэмин итү | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | жирле бюджет | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 6. | Физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә җитәкче хезмәткәрләр, белгечләр һәм иҗтимагый актив белән ел саен үткәрелә торган республика семинар-киңәшмәләрендә катнашу | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | жирле бюджет | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 | 6,0 |
| 7. | Физик культура һәм спорт өлкәсе тренерларын, җитәкчеләрен һәм белгечләрен яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрү | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | жирле бюджет | 8,0 | 8,0 | 8,0 | 8,0 | 8,0 |
| 8. | "Спорт – тормыш нормасы" федераль проекты кысаларында | Спорт һәм туризмны үстерү | 2020-2024 | республи-ка | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | кече спорт мәйданчыклары булдыру өчен спорт-технологик җиһазлар сатып алу | бүлеге Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “1нче спорт мәктәбе” МБУ (алга таба – “1нче СМ” МБУ) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “2нче спорт мәктәбе” МБУ (алга таба – “2нче СМ” МБУ) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының “3нче комплекслы спорт мәктәбе” МАУ (алга таба – “3нче КСМ” МАУ) | еллар | бюджеты | | | | | |
| 9. | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын һәм аны үтәүгә әзерлек системасын популярлаштыру | Спорт һәм туризмны үстерү бүлеге | 2020-2024 еллар | җирле бюджет | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 20,0 |
| | | | | | 1 203, | 1 203, | 1 203, | 1 203, | 1 203, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| БАРЛЫГЫ: | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 |

II. Баулы муниципаль районында физик культура учреждениеләрен үстерү буенча чаралар исемлеге

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Спорт әзерлеге ведомствосы учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итү | “1нче СМ” МБУ<br>“2нче СМ” МБУ<br>“3нче КСМ” МАУ | 2020-2024 еллар | жирле бюджет | 54 923,1 | 54 263,1 | 54 708,0 | - | - |
| БАРЛЫГЫ: | | | | | 54 923,1 | 54 263,1 | 54 708,0 | - | - |

III.“2020-2024 елларга югары казанышлар спортын һәм спорт резервын әзерләү системасын үстерү” ярдәмче программасы чаралары исемлеге

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Спорт мәктәпләрен махсус җиһазлар, спорт инвентаре һәм экипировка белән тәэмин итү | “1нче СМ” МБУ<br>“2нче СМ” МБУ<br>“3нче КСМ” МАУ | 2020-2024 еллар г | республика бюджеты | 335,40 | - | - | - | - |
| 2. | Хоккей буенча Татарстан Республикасы һәм Россия беренчелегендә катнашу (А төркеме) | “3нче КСМ” МАУ | 2020-2024 еллар | республика бюджеты | 272,40 | - | - | - | - |
| БАРЛЫГЫ: | | | | | 607,80 | - | - | - | - |

---